Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге
Акбаш торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

№4 15 ноябрь 2024 ел

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге Акбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пунктында юлларның чокырларын ремонтлау);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (Акбаш торак пунктында юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)» юлларга.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында эләргә.

Гражданнар җыенанда рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге башлыгы И.Р.Сәхибуллина